РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
16.12.2024

КАРАР
№28

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Шыңар авыл
җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 23.10.2024 ел 22нче номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен карап тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елда "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы турында» 31 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә

2.Әлеге карарны “Интернет”мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:
- ТР, Саба районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36; ТР, Саба районы, Кече Шыңар авылы, Кооператив урамы, 21; ТР, Саба районы, Оет авылы, Ленин урамы, 38; ТР, Саба районы,Чулпыч авылы, Г.Тукай урамы, 11

3.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм естәмәләр дәүләт теркәве өчен әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов

КУШЫМТА
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2024 елның 16 нчы декабрендә чыккан 28нче номерлы " Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» карарына

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә:: «21 шәхси ярдәмче хуҗалык турында " 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алу.»;
2. 5 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип таныргa;
3. 19 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1 – 7 һәм 9.2 пунктларында»сүзләренә алмаштырырга.;
4. 34 статьяның 1 пунктындагы 26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: «26) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) Челтәр басмасын булдыру;»;
5. 41 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.1 пунктчасы өстәргә:: "12.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;
6. 50 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчага түбәндәге эчтәлекле өченче абзац естәргә:: - «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.»;
7. 50 статьяның 1 пунктындагы 6 пунктчасының өченче абзацын үз көчен югалткан дип таныргa; 8. 59 статьяның 3 пунктын үз кечен югалткан дип таныргa;
9. 73 статьяның 9 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: - хокукый актның тулы текстын элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән вакытлы матбугат басмасы - « Саба таңнары” район газетасында бастырып чыгару (ПИ ММЧны теркәү турында ТУ16-01686 номерлы таныклык 10.10.2019 елда элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан бирелгән). Муниципаль хокукый акт басылып чыкканда матбугат чараларының чыгу датасы күрсәтелергә тиеш
10. 73 статьяга түбәндәге эчтәлекле 11 пункт естәргә:: «11. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив ур., 37 йорт(авыл китапханәсе).».